СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**20.09.2017**

Зеленодольск ш.

**КАРАР**
**№ 143**

Зеленодольск шәһәре Советының 2006 елның 1 мартындагы 26 нчы номерлы карары белән расланган депутат статусы турында нигезләмәгә өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Зеленодольск шәһәре Советы регламентының 2 бүлеге нигезендә, законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясе рәисе Афиногенов А. В. ның мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. 2006 елның 1 марты 26 нчы номерлы карары белән расланган Зеленодольск шәһәре Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге өстәмә кертергә:

19.1 маддәне киләсе эчтәлек белән тулыландырырга:

**"19.1 Маддә. Депутат ярдәмчеләре"**

1. Депутат үзенә депутатлык эшчәнлеген тормышка ашыруда ярдәм итәр өчен өч ярдәмче алырга хокуклы. Депутат ярдәмчеләренең эше (эшчәнлеге) иҗтимагый башлангычларда башкарыла.

2. Депутат үз ярдәмчеләре өчен җаваплы һәм аларны теләсә кайсы вакытта алыштырырга хокуклы.

3. Депутат ярдәмчеләре эшенең (эшчәнлегенең) хокукый нигезләре шәһәр Советы тарафыннан раслана торган нигезләмә белән билгеләнә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск шәһәре мэры,**
**Совет рәисе** **А.В. Тыгин**